# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АЙДАР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
# КАРАР
**кырык беренче утырыш дүртенче чакырылыш**

28 апрель 2025 ел № 123 Айдар ав.

Айдар авыл җирлеге Советының 2018 елның 21 маендагы 99 номерлы «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Айдар авыл җирлеге җирле үзидарә органы депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының һәм муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмә хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 14 апрелендәге 228 номерлы «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары, муниципаль хезмәткәрләр аудиторлары, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәт өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» карары нигезендә, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Айдар авыл җирлеге Советы карар итте,

1. Айдар авыл җирлеге Советының 2018 елның 21 маендагы 99 номерлы «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Айдар авыл җирлеге җирле үзидарә органы депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының һәм муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмә хакында» карарына ( от 19.09.2018 ел №101; 09.10.2018 ел №109; 20.12.2018 ел №117, 08.05.2019 ел №132; 29.08.2019 ел №136; 24.10.2022 ел № 60, 16.12.2022 ел №63, 28.06.2024 ел № 102 карарлар редакциясендә) (алга таба текст буенча - карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның 1 пунктын түбәндәге эчтәлектә бәян итәргә:

«1. Авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи окладын 15 389 сум күләмендә расларга.».

1.2. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органнары депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына һәм муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турындагы Нигезләмәнең 11.5 пунктын түбәндәге эчтәлектә бәян итәргә:

«11.5. Вазыйфаи окладның 1 процентыннан артмаган күләмдә ай саен акчалата бүләкләү, моңа муниципаль хезмәткәрнең җирле үзидарә органнары структурасы стандартларын муниципаль хезмәт вазыйфасына азрак вазыйфаи

оклады белән билгеләнгән муниципаль хезмәт вазыйфасына кертү белән бәйле рәвештә җирле үзидарә органнары структурасын үзгәртеп корганда билгеләнгән очрак керми, мондый очракта акчалата бүләкләү күләме муниципаль хезмәткәрнең акчалата күләмен элек билгеләнгән вазыйфасы буенча акчалата түләү күләменә җиткерүне тәэмин итүне исәпкә алып башкарыла.».

1.3. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органы депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының һәм муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмәнең 20 пунктының 6 пунктчасын түбәндәге эчтәлектә бәян итәргә:

«6) айлык акчалата бүләкләү - вазыйфаи окладларның 58 процентыннан артмаган күләмдә.».

Карарның 2 номерлы кушымтасын түбәндәге эчтәлектә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Айдар авыл җирлеге Советының 2018 елның 21 маендагы № 99 Советы карарына 2 номерлы кушымта

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Айдар авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгын, депутатларны, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларын айлык акчалата бүләкләү күләмнәре

| Вазыйфалар исемнәре | Айлык акчалата түләү, сум |
|---|---|
| | 12 төркем |
| 1 | 2 |
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 21 091 |
| Муниципаль берәмлек Башлыгы урынбасары | 15 391 |

2. Әлеге карар 2025 елның 1 маеннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Айдар авыл җирлеге башлыгы: Х.Ш. Хасаншин